КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 ноябрь г.Казань № 1010

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 ел, 28 сентябрь, 879 нчы карары белән расланган Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 ел, 28 сентябрь, 879 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 05 декабрь, 1280 нче, 2023 ел, 13 май, 590 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктта «республика территориаль ярдәмче челтәре» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы территориясендә яисә аның аерым җирлекләрендә тулы күләмдә яисә өлешчә» сүзләрен өстәргә;

1.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«кирәк булганда, радиацион, химик һәм биологик хәлнең торышын күзәтү һәм лаборатория контроле максатларында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары белән мәгълүмати хезмәттәшлек турында тиешле килешүләр төзиләр.»;

3.4 пунктта:

беренче абзацта «куркыныч табылганнан соң бер сәгатьтән дә соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «куркыныч табылганнан соң бер сәгатьтән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «мәгълүмат алганнан соң бер сәгатьтән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Республика территориаль ярдәмче челтәренең тиешле дәрәҗәләрдә гражданнар оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыручы органнар белән үзара хезмәттәшлеге гражданнар оборонасы белән идарә итүне тәэмин итә торган идарә пунктларыннан һәм техник чаралардан файдаланып гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин